| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 17.09.2019 | Казан ш. | № 261 |

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә 2019 елның август аенда коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләменең чик дәрәҗә (максималь) индексларын үтәүгә мониторинг нәтиҗәләре турында хисап раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләргә гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләренә ярашлы рәвештә,

Б О Е Р Ы К   Б И Р Ә М :

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә 2019 елның август аенда коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләменең чик дәрәҗә (максималь) индексларын үтәүгә мониторинг нәтиҗәләре турында хисапны расларга (кушымтада бирелә) (алга таба – мониторинг нәтиҗәләре турында хисап).

2. Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлегенә әлеге боерыкны, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштыру өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Мәгълүматлаштыру бүлегенә мониторинг нәтиҗәләре турында хисапны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәсми сайтында (www.kt.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге боерык аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.В.Хәбибуллинга йөкләргә.

Рәис А.С.Груничев

Кушымта

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.09.2019 № 261 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә 2019 елның август аенда коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләменең чик дәрәҗә (максималь) индексларын үтәүгә мониторинг нәтиҗәләре турында хисап

Россия Федерациясе Торак кодексының 157.1 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләргә гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карарына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 15 ноябрендәге 2490-р номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Президентының «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик дәрәҗә (максималь) индекслары турында» 2018 елның 14 декабрендәге ПУ-851 номерлы Указына ярашлы рәвештә 2019 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре буенча коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик дәрәҗә (максималь) индекслары (алга таба – чик дәрәҗә индекслар) расланды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләргә гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләргә гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләренең 61 пунктын үтәү максатында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан 2019 елның август аенда Татарстан Республикасының 913 муниципаль берәмлеге кисемендә чик дәрәҗә индексларның үтәлешенә мониторинг ясалды.

Күрсәтелгән мониторинг нәтиҗәләре буенча 2019 елга билгеләнгән чик дәрәҗә индексларның күрсәткечләрен арттыру очраклары ачыкланмады.